**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О республиканском звании**
**«Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.»**

В целях сохранения военно-исторического и трудового наследия промышленных предприятий, которые внесли значительный вклад в достижение Победы в Великой Отечественной войне 1941–1945 годов, обеспечив бесперебойное производство военной и гражданской продукции, а также увековечения памяти о массовом трудовом героизме и самоотверженности работников, осуществлявших трудовую деятельность на указанных предприятиях в годы Великой Отечественной войны, **постановляю:**

1. Учредить республиканское звание «Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.».

2. Утвердить Положение о республиканском звании «Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.» (приложение № 1) и описание свидетельства о присвоении республиканского звания «Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.» (приложение № 2).

3. Кабинету Министров Республики Татарстан:

обеспечить в установленном порядке финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа;

привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
12 апреля 2022 года
№ УП-266

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «12» апреля 2022 года

№ УП-266

**Положение**
**о республиканском звании «Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.»**

1. Республиканское звание «Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.» присваивается промышленным предприятиям, расположенным и осуществляющим свою деятельность на территории Республики Татарстан, являющимся правопреемниками промышленных предприятий, которые внесли значительный вклад в достижение Победы в Великой Отечественной войне 1941–1945 годов, обеспечив бесперебойное производство военной и гражданской продукции благодаря массовому трудовому героизму и самоотверженности их работников (далее соответственно – республиканское звание, предприятия-правопреемники, предприятия).

2. Основаниями для присвоения республиканского звания являются документально подтвержденный факт награждения предприятия государственной наградой СССР за обеспечение выпуска продукции в период Великой Отечественной войны, и (или) факт вручения предприятию переходящего Красного знамени Государственного Комитета Обороны, и (или) факт (факты) награждения работников предприятия государственными наградами за трудовые заслуги в период Великой Отечественной войны.

3. Ходатайство о присвоении республиканского звания направляется руководителем предприятия-правопреемника в межведомственную комиссию, образованную Кабинетом Министров Республики Татарстан, в компетенцию которой входит рассмотрение вопросов увековечения памяти о массовом трудовом героизме и самоотверженности работников предприятий, внесших значительный вклад в достижение Победы в Великой Отечественной войне 1941–1945 годов (далее – межведомственная комиссия).

4. К ходатайству о присвоении республиканского звания прилагаются:

копия устава предприятия-правопреемника;

протокол (выписка из протокола) собрания, конференции коллектива работников предприятия-правопреемника, содержащий (содержащая) решение о возбуждении ходатайства о присвоении республиканского звания;

копии документов, подтверждающих наличие основания (оснований) для присвоения республиканского звания;

заключение государственного научного бюджетного учреждения «Академия наук Республики Татарстан» о наличии основания (оснований) для присвоения республиканского звания.

5. Ходатайство о присвоении республиканского звания предварительно согласуется с главой муниципального района (городского округа) Республики Татарстан, на территории которого расположено предприятие-правопреемник, а также с руководителем исполнительного органа государственной власти Республики Татарстан, осуществляющего управленческие функции (функциональное регулирование) в сфере деятельности, соответствующей основному виду деятельности предприятия-правопреемника. Указанное согласование осуществляется в произвольной форме на бумажном носителе или в электронной форме посредством единой межведомственной системы электронного документооборота Республики Татарстан.

6. Межведомственная комиссия в течение 30 календарных дней со дня поступления ходатайства о присвоении республиканского звания рассматривает его и принимает одно из следующих решений:

обратиться к Президенту Республики Татарстан с предложением о присвоении республиканского звания;

отклонить ходатайство о присвоении республиканского звания.

7. Основаниями для отклонения ходатайства о присвоении республиканского звания являются:

отсутствие оснований для присвоения республиканского звания;

недостоверность сведений, содержащихся в ходатайстве о присвоении республиканского звания и приложенных к нему документах;

неполнота документов, прилагаемых к ходатайству о присвоении республиканского звания.

8. Об отклонении ходатайства о присвоении республиканского звания межведомственная комиссия уведомляет руководителя предприятия-правопреемника в течение семи календарных дней со дня принятия соответствующего решения с указанием причин отклонения.

В случае устранения причин отклонения ходатайства оно может быть направлено повторно.

9. При принятии решения об обращении к Президенту Республики Татарстан с предложением о присвоении республиканского звания межведомственная комиссия направляет в установленном порядке соответствующее обращение Президенту Республики Татарстан.

К обращению прилагаются:

протокол заседания межведомственной комиссии;

ходатайство предприятия-правопреемника и прилагаемые к нему документы;

проект указа Президента Республики Татарстан о присвоении республиканского звания.

10. Республиканское звание присваивается указом Президента Республики Татарстан.

11. Предприятию-правопреемнику, удостоенному республиканского звания, в торжественной обстановке вручается свидетельство о присвоении республиканского звания, подписываемое Президентом Республики Татарстан. Указанное свидетельство вручается Президентом Республики Татарстан либо по его поручению руководителями государственных органов Республики Татарстан.

12. Изготовление, хранение бланков свидетельств о присвоении республиканского звания, подготовка и представление на подписание Президенту Республики Татарстан свидетельств о присвоении республиканского звания, а также учет выданных свидетельств о присвоении республиканского звания осуществляются Министерством промышленности и торговли Республики Татарстан.

13. Республиканское звание присваивается предприятию-правопреемнику однократно. При утере свидетельства о присвоении республиканского звания дубликат не выдается.

14. Предприятие-правопреемник, удостоенное республиканского звания, имеет право на публичное использование республиканского звания, а также на изготовление и установку за счет собственных средств мемориальной доски, эскиз которой утверждается Комиссией по мемориальным доскам при Министерстве культуры Республики Татарстан. Установка мемориальной доски осуществляется на территории предприятия-правопреемника.

15. Государственные органы Республики Татарстан, органы местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан и подведомственные им организации при проведении торжественных мероприятий, посвященных Дню Победы, другим памятным датам и праздничным дням, приглашают для участия в них представителей предприятий-правопреемников, удостоенных республиканского звания.

---

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 12 » апреля 2022 года

№ УП-266

**Описание**
**свидетельства о республиканском звании «Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.»**

Свидетельство о присвоении республиканского звания «Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.» (далее – свидетельство) представляет собой лист мелованной матовой бумаги формата А3 (297 х 420 мм), расположенный горизонтально.

Лицевая сторона листа по периметру на расстоянии 10 мм от края листа обрамлена орнаментом, заключенным в рамку шириной 16,5 мм, выполненным офсетной печатью.

Текст свидетельства располагается на фоне защитной тангирной сетки и помещается в рамку темно-бордового цвета, расположенную на расстоянии 30 мм от края листа.

Сверху по центру на расстоянии 45 мм от верхнего края листа изображен Государственный герб Республики Татарстан диаметром 26 мм, выполненный золотым тиснением.

Сверху слева и справа от Государственного герба Республики Татарстан расположены в одну строку слова: «ПРЕЗИДЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» и «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ» соответственно, выполненные офсетной печатью, заглавными буквами высотой 4 мм.

Ниже слева от Государственного герба Республики Татарстан на расстоянии 30 мм от строки «ПРЕЗИДЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» расположены слова: «СВИДЕТЕЛЬСТВО о присвоении республиканского звания «ПРЕДПРИЯТИЕ ТРУДОВОЙ ДОБЛЕСТИ. 1941–1945 ГГ.», выполненные золотым тиснением, буквами высотой 7 мм (заглавные) и 4,5 мм (строчные).

Ниже справа от Государственного герба Республики Татарстан на расстоянии 30 мм от строки «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ» расположены слова: «ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕСЕ. 1941–1945 ЕЛЛАР» республика исемен бирү турында ТАНЫКЛЫК», выполненные золотым тиснением, буквами высотой 7 мм (заглавные) и 4,5 мм (строчные).

С левой стороны листа ниже слов «СВИДЕТЕЛЬСТВО о присвоении республиканского звания «ПРЕДПРИЯТИЕ ТРУДОВОЙ ДОБЛЕСТИ.

1941–1945 ГГ.» на расстоянии 15 мм буквами темно-бордового цвета высотой 4 мм (заглавные) и 3 мм (строчные) печатается текст:

«Указом Президента Республики Татарстан от «___» ________________
20__года № УП-___ ________________________________________________
(наименование предприятия)

присвоено республиканское звание «Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.»».

С правой стороны листа ниже слов «ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕСЕ. 1941–1945 ЕЛЛАР» республика исемен бирү турында ТАНЫКЛЫК» на расстоянии 15 мм буквами темно-бордового цвета высотой 4 мм (заглавные) и 3 мм (строчные) печатается текст:

«Татарстан Республикасы Президентының 20_____елның «___»____________ПУ-____номерлы Указы нигезендә__________________
_____________________________________________________________________
(предприятиенең атамасы)

«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирелде».

Ниже текста на расстоянии 15 мм по центру располагается подпись Президента Республики Татарстан и расшифровка подписи, которая состоит из инициала имени, инициала отчества и фамилии Президента Республики Татарстан, напечатанных заглавными буквами темно-бордового цвета высотой 4 мм, слева – на русском, справа – на татарском языках.

Ниже по центру расположены слова: «Казань, Кремль», напечатанные буквами темно-бордового цвета высотой 4 мм (заглавные) и 3 мм (строчные).

___________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында**

Хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин итеп, 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләренең хәрби-тарихи һәм хезмәт мирасын саклау, шулай ук Бөек Ватан сугышы елларында әлеге предприятиеләрдә эшләгән хезмәткәрләрнең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге турындагы хатирәләрне мәңгеләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен гамәлгә куярга.

2. «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен бирү турында таныклыкның тасвирламасын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;
үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 12 апрель
№ ПУ-266

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «12» апрелендәге
ПУ-266 номерлы Указына
1 нче кушымта

**«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында нигезләмә**

1. «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм эшчәнлек алып барган, хезмәткәрләрнең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге нәтиҗәсендә хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин итеп, 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләренең хокукый дәвамчылары булган сәнәгать предприятиеләренә (алга таба тиешенчә – республика исеме, предприятиеләр-хокукый дәвамчылар, предприятиеләр) бирелә.

2. Предприятиенең Бөек Ватан сугышы чорында продукция эшләп чыгаруны тәэмин иткәне өчен документлар белән расланган СССР дәүләт бүләге белән бүләкләнүе факты һәм (яисә) предприятиегә Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл байрагы тапшырылу факты һәм (яисә) Бөек Ватан сугышы чорында предприятие хезмәткәрләренең хезмәттәге казанышлары өчен дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүе факты (фактлары) республика исемен бирүгә нигез булып тора.

3. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамә предприятие-хокукый дәвамчы җитәкчесе тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты оештырган, 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткән предприятиеләр хезмәткәреләрнең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге турындагы хатирәләрне мәңгеләштерү мәсьәләләрен карарга вәкаләтле ведомствоара комиссиягә (алга таба – ведомствоара комиссия) җибәрелә.

4. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамәгә түбәндәгеләр теркәп бирелә:

предприятие-хокукый дәвамчы уставы күчермәсе;

предприятие-хокукый дәвамчы хезмәткәрләренең җыелышының, конференциясенең республика исемен бирү турында үтенечнамә бирүгә бәйле эш башлау турында карары кертелгән беркетмә (беркетмәдән өзек);

республика исемен бирү өчен нигез (нигезләр) булуын раслый торган документлар күчермәләре;

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең республика исемен бирү өчен нигез (нигезләр) булуы турында бәяләмәсе.

5. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамә башта территориясендә предприятие-хокукый дәвамчы урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы, шулай ук предприятие-хокукый дәвамчының төп эшчәнлеге рәвешенә туры килгән эшчәнлек даирәсендә идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салуны) башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесе белән килештерелә. Әлеге килештерү Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә кәгазь чыганакта ирекле формада башкарыла.

6. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамә алынган көннән 30 календарь көн эчендә ведомствоара комиссия аны карап тикшерә һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

республика исемен бирү турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы Президентына мөрәҗәгать итәргә;

республика исемен бирү турындагы үтенечнамәне кире кагарга.

7. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамәне кире кагу өчен нигезле сәбәпләр түбәндәгеләр:

республика исемен бирү өчен нигез булмау;

республика исемен бирү турындагы үтенечнамәдәге һәм аңа теркәп бирелгән документлардагы мәгълүматларның дөреслеккә туры килмәве;

республика исемен бирү турындагы үтенечнамәгә теркәп бирелгән документларның тулы булмавы.

8. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамәнең кире кагылуы турында ведомствоара комиссия предприятие-хокукый дәвамчы җитәкчесенә, кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге карар кабул ителгән көннән җиде календарь көн дәвамында хәбәр бирә.

Үтенечнамәне кире кагу сәбәпләре бетерелгән очракта, ул кабаттан юлланырга мөмкин.

9. Республика исемен бирү турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы Президентына мөрәҗәгать итәргә дигән карар кабул ителгән очракта, ведомствоара комиссия билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына тиешле мөрәҗәгатьне юллый.

Мөрәҗәгатькә түбәндәгеләр теркәп бирелә:

ведомствоара комиссия утырышы беркетмәсе;

предприятие-хокукый дәвамчының үтенечнамәсе һәм аңа теркәп бирелә торган документлар;

Татарстан Республикасы Президентының республика исемен бирү турындагы указы проекты.

10. Республика исеме Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә бирелә.

11. Республика исеменә лаек булган предприятие-хокукый дәвамчыга Татарстан Республикасы Президенты кул куйган республика исемен бирү турындагы таныклык тантаналы шартларда тапшырыла. Әлеге таныклыкны

Татарстан Республикасы Президенты яисә аның йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләре тапшыра.

12. Республика исемен бирү турындагы таныклык бланкларын эшләү, саклау, республика исемен бирү турындагы таныклыкларны әзерләү һәм кул кую өчен Татарстан Республикасы Президентына тапшыру, шулай ук республика исемен бирү турындагы таныклыкларны исәпкә алу Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан башкарыла.

13. Республика исеме предприятие-хокукый дәвамчыга бер тапкыр бирелә. Республика исемен бирү турындагы таныклыкны югалткан очракта, дубликат бирелми.

14. Республика исеменә лаек булган предприятие-хокукый дәвамчының республика исемен ачыктан-ачык файдаланырга, шулай ук үз акчасына эскизы Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Мемориаль такталар буенча комиссия тарафыннан раслана торган мемориаль такта ясатырга һәм куярга хокукы бар. Мемориаль такта предприятие-хокукый дәвамчы территориясендә куела.

15. Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм алар карамагындагы предприятиеләр Җиңү Көненә, башка истәлекле даталарга һәм бәйрәм көннәренә багышланган тантаналы чаралар уздырганда, аларда катнашу өчен республика исеменә лаек булган предприятие-хокукый дәвамчы вәкилләрен чакыра.

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 12 » апрелендәге
ПУ- 266 номерлы Указына
2 нче кушымта

**«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында таныклыкның тасвирламасы**

«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен бирү турында таныклык (алга таба – таныклык) горизонталь А3 (297 х 420 мм) форматындагы ялтыравыксыз ак кәгазь битеннән гыйбарәт.

Битнең алгы ягына бит кырыеннан 10 мм ара калдырып офсет ысулы белән басылган 16,5 мм киңлектәге кыса эченә урнаштырылган бизәк төшерелгән.

Таныклыкның тексты саклагыч тангир челтәрле җирлектә бит кырыеннан 30 мм ара калдырып урнаштырылган куе кызыл төстәге кыса эчендә бирелә.

Битнең өске кырыеннан 45 мм ара калдырып өске якта уртада 26 мм диаметрлы алтын бизәк рәвешендә тыгызлап басылган Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан өстә тиешенчә сул һәм уң якта бер юлга офсет ысулы белән басылган 4 миллиметрлы баш хәрефләрдән: «ПРЕЗИДЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» һәм «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ» сүзләре урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан аста сул якта «ПРЕЗИДЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» сүзләреннән 30 мм ара калдырып алтын бизәк рәвешендә басылган 7 миллиметрлы (баш хәрефләр) һәм 4,5 миллиметрлы (юл хәрефләре) хәрефләрдән: «СВИДЕТЕЛЬСТВО о присвоении республиканского звания «ПРЕДПРИЯТИЕ ТРУДОВОЙ ДОБЛЕСТИ. 1941–1945 ГГ.» сүзләре урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан аста уң якта «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ» сүзләреннән 30 мм ара калдырып алтын бизәк рәвешендә тыгызлап басылган 7 миллиметрлы (баш хәрефләр) һәм 4,5 миллиметрлы (юл хәрефләре) хәрефләрдән: «ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕСЕ. 1941–1945 ЕЛЛАР» республика исемен бирү турында таныклык» сүзләре урнаштырылган.

Битнең сул ягында «СВИДЕТЕЛЬСТВО о присвоении республиканского звания «ПРЕДПРИЯТИЕ ТРУДОВОЙ ДОБЛЕСТИ. 1941–1945 ГГ.» сүзләреннән 15 мм аскарак 4 миллиметрлы (баш хәрефләр) һәм 3 миллиметрлы (юл хәрефләре) куе кызыл төстәге хәрефләрдән түбәндәге текст урнаштырыла:

«Указом Президента Республики Татарстан от «___» ___________20__года № УП- ____ ______________________________

______________________________________________________________

(наименование предприятия)

присвоено республиканское звание «Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.».

Битнең уң ягында «ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕСЕ. 1941–1945 ЕЛЛАР» республика исемен бирү турында таныклык» сүзләреннән 15 мм аскарак 4 миллиметрлы һәм 3 миллиметрлы куе кызыл төстәге хәрефләрдән түбәндәге текст урнаштырыла:

«Татарстан Республикасы Президентының 20___ елның «___»____________ПУ-____номерлы Указы нигезендә_________________

______________________________________________________________

(предприятиенең атамасы)

«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирелде».

Тексттан 15 мм астарак уртада Татарстан Республикасы Президенты имзасы һәм рус телендә – сул якта, татар телендә – уң якта куе кызыл төстәге 4 миллиметрлы баш хәрефләрдән Татарстан Республикасы Президентының исеменең беренче хәрефе, атасының исеменең беренче хәрефе һәм фамилиясе рәвешендә аның имзасының шәрехләмәсе урнаштырыла.

Аскы якта уртада 4 миллиметрлы (баш хәрефләр) һәм 3 миллиметрлы (юл хәрефләре) куе кызыл төстәге хәрефләрдән: «Казань, Кремль» сүзләре урнаштырыла.

___________